Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

“11 ” июнь 2021 ел № 29

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советының 2007 елның 29 июнендә 66 номерлы карар белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советының 29.06.2007 ел, № 66 карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

1) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле икенче жомлэ өстәргә::

«Инициативалы проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча гражданнар арасында үткәрелгән сораштыруда Олы Карамалы авыл җирлеге яисә аның өлешендә яшәүчеләр (16 яше тулган) катнашырга хокуклы.”;

2) 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Гражданнарны сораштыру, уналтынчы яшькә җиткән инициативалы проектны тормышка ашыру тәкъдим ителә торган Олы Карамалы авыл җирлегендә яшәүчеләр инициативасы белән, әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен үткәрелә.»;

3) 8 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«1. Гражданнарны сораштыруны билгеләү турында карар Олы Карамалы авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен Олы Карамалы авыл җирлегенең рәсми сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә файдаланылырга мөмкин. Олы Карамалы авыл

җирлеге Советының гражданнар арасында сораштыру билгеләү турындагы карарында билгеләнә:

1) сораштыру үткәрү датасы һәм сроклары;

2) Сораштыру уздырганда тәкъдим ителә торган сорауны (сорауларны) формулировкалау;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазе формасы;

5) сораштыруда катнашучы җирлек халкының минималь саны;

6) җирлекнең «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан файдаланып, гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.»;

4) 23 статьяның 1 пунктына «җирлек халкы өчен» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга (kamskoye-ustye.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгы,
Олы Карамалы авыл җирлеге Советы рәисе Э.И.Байдамшин